14 февраль – Гашыйклар көне! (Бәзәкә авылы мәдәният йорты)

Мәдәният йорты һәм китапханә хезмәткәрләре гашыйклар көне уңаеннан “Ике аккош” дип исемләнгән конкурс-кичә оештырдылар.

Гашыйклар бәйрәме ул – серле, мавыктыргыч, күңелллләргә яктылык, нур иңдерүче, күзләргә очкын бирүче, канатландыручы, матур җырлар, шигырьләр, сәнгать әсәрләре иҗат итәргә этәрүче бәйрәм, чөнки ул яратучылар, сөю ялкыннарында янучылар бәйрәме. Менэ шундый гашыйк җаннарны үзенә җыйды мәдәният йорты.  Кичә бик күнелле булды, гашыйк җаннар үз парларын тапты. Конкурста һәр пар үз номинациясендә җиңү яулады. Гузәл бәйрәмнең истәлекле бүләкләре дә тапшырылды.

Чыннан да, җир йөзендә мәхәббәттән дә гүзәлрәк, татлырак хис бар микән ул?! Бу хистән башка дөньяда яшәүнең яме генә түгел, мәгънәсе дә булмас иде. Яратканда нәрсә өчендер түгел, ә бернигә дә карамастан яратасың. Дөньяда һәр кеше сөяргә һәм сөелергә хаклы, һәр кеше хыялый мәхәббәткә табынып, ышанып, омтылып яши.




МӘХМҮТОВА


МӘХМҮТОВА













